ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 ел, «3» сентябрь** **№ 692**

**Башкарма комитетның “Балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларының матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчаларны җәлеп итү турында” 2016 елның 1 нче мартындагы 206 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алына торган керемнәр, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, күләмен һәм әлеге керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнар күләмен арттыру максатларында, Арча районы башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 1 нче мартындагы 206 номерлы «Арча муниципаль районының өстәмә белем бирү муниципаль белем бирү оешмаларының матди-техник базасын үстерү һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» (2017 елның 20 гыйнварындагы 20 номерлы, 2018 елның 31 августындагы 735 номерлы, 2018 елның 25 декабрендәге 1257 номерлы, 2019 елның 25 гыйнварындагы 22 номерлы үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

"Арча спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесе буенча 1 нче кушымтада

- спорт төрләре буенча Спорт дәресләренең (тренер белән) бәясе турында таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Спорт төрләре буенча спорт дәресләре (тренер белән)

| Килүчеләр | Спорт төре | Атнага дәресләр саны | 1 дәреснең дәвамы, мин. | Аена абонент бәясе, сум |
|---|---|---|---|---|
| Яшь буенча чикләүсез гражданнар | Футбол | 2 | 45 | 600 |
| | Тхэквондо | 2 | 45 | 600 |
| | Йөзү | 2 | 45 | 600 |

- спорт залын арендалау бәясе турында таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Спорт залын арендалау

| Килүчеләр | Бәясе (1 сәгать өчен), сум |
|---|---|
| Өлкәннәр (18 яшь һәм өлкәнрәк) | 1000 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматлар порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И.Гарифҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә. Галимуллин